**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИХАЙЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ L УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 79**

Михайловка ав. 6 сентябрь 2024 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2018 елның “26” ноябрь 31 номерлы Михайловка авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2018 елның “26” ноябрь 31 номерлы Михайловка авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 1.1. пунктчасы белән тулыландырырга:

«1.1) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата 1,2 процент.»;

1.2. Карарны түбәндәге эчтәлекле 3.3. пункты белән тулыландырырга:

«3.3. Әлеге карарның 2 пунктының 1.1. нче пунктчасы 31.12.2027 елга кадәр гамәлдә. ».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

**Михайловка авыл җирлеге башлыгы** **Н.А. Ращупкина**